ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.03.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 688**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 794 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартларына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 1 апрелендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» 314 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 18 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларына үзгәрешләр кертү хакында» 1148 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору турында» 794 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск шәһәре» муниципаль

берәмлеге һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган торышы буенча бирелә»;

3пунктта

беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектереп тору тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә.».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев